| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** Казань **БОЕРЫК**

22.09.2017 № 524

**Татарстан Республикасы**
**Гражданнар оборонасы эшләре һәм**
**гадәттән тыш хәлләр министрлыгы**
**карамагында иҗтимагый совет турында**

“Русия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында” 2014 ел 21 июль № 212-ФЗ Федераль законына, “Татарстан Республикасы министрлыгы (идарәчелеге) карамагында иҗтимагый совет турында” 2010 ел 18 ноябрь № 906 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына (15.10.2011 № 856, 24.10.2013 № 793, 20.09.2014 № 669, 14.05.2015 № 341, 05.09.2015 № 643, 17.11.2015 № 862 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) туры китереп, б о е р а м:

1. Кушылган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы карамагында иҗтимагый совет турында кагыйдәнамәне расларга.

2. Боерыкны үтәү контролен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

2017 ел 22 сентябрь № 524
Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ КАРАМАГЫНДА ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДА КАГЫЙДӘНАМӘ

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы карамагында иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасында туры килгән өлкәдә дәүләт политикасын формалаштырганда һәм тормышка ашырганда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган башка комеррциясез оешмаларның хокукларын, яхшы сыйфатлы социаль уңайлыкларны күрсәтүгә гражданнарның хокукларын реальләштерү белән бәйле сорауларны, халыкка социаль уңайлыклар күрсәтү өлкәсендә аларның нәтиҗәлеген һәм иминлеген сынау, дәүләти контроль һәм күзәтүне камилләштерү сорауларын карап тикшерә торган, шулай да биредәге Кагыйдәнамәдә язылган башка вәкаләтне башкара торган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – Министрлык) карамагында киңәш органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – Министр) боерыгы белән раслана.

1.3. Үзенең эшендә Иҗтимагый совет Русия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Русия Федерациясе указларын һәм әмерләрен, Русия Федерациясе Хөкүмәте карарларын һәм әмерләрен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмерләрен, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларын һәм әмерләрен, шулай да биредәге Кагыйдәнамәне кулланып эш итә.

1.4. Иҗтимагый советның карарлары тәкъдим характерын йөртәләр.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшен иҗтимагый нигезләрдә башкара.

1.6. Иҗтимагый советның эше ачыклык һәм партнерлык принципларында һәм нәкъ Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп ирекле нигездә төзелә.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданнар җәмгыяте, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары институтларының, массакүләм мәгълүмат

чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә башкара.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләте

2.1. Иҗтимагый совет эшенең төп максатлары түбәндәгеләр булып тора:

гражданнар оборонасы, муниципальара һәм региональ сыйфатта гадәттән тыш хәлләрне, бәла-казаларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү, янгыннар сүндерүне оештыру, су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә (алга таба – туры килгән өлкәдә) дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм башкарганда Русия Федерациясе гражданнарының кирәкләрен һәм кызыксынуларын исәпкә алу, Русия Федерациясе гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын яклау;

туры килгән эш өлкәсенә бәйле булган сораулар буенча, Министрлык эшенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принцибын тормышка ашыру буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләп чыгаруга иҗтимагый, профессиональ һәм иҗади берләшмәләрнең вәкилләрен тарту;

Министрлык карамагында булган дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт уңайлыкларның иҗтимагый сыйфат контролен көчәйтү, туры килгән өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары түбәндәгеләр булып тора:

туры килгән өлкәдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәрне хәзерләү;

туры килгән эш өлкәсе сораулары белән бәйле норматив хокук акт проектларының иҗтимагый экспертизасын үткәрү, шул исәптән Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы эшләп чыгара торган дәүләт программасы проектлары турында фикер алышу;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы карарлар кабул иткәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының төп эш юнәлешләре буенча җәмгыятьнең хәбәрдарлыгын арттыру;

социаль хезмәт күрсәтү, социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәләрендә оешмалар (учреждениеләр) күрсәтә торган уңайлыклар сыйфатының бәйсез сынавын үткәрү.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурчылары, аның эш нәтиҗәләренә карап һәм Русия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси хәлне исәпкә алып, үзгәрергә һәм тулыланырга мөмкин.

2.4. Социаль хезмәт күрсәтү, социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәләрендә оешмалар (учреждениеләр) күрсәтә торган уңайлыклар сыйфатының бәйсез сынавын башкарыр өчен Иҗтимагый совет:

бәйсез сынау үткәрелә торган оешмаларның (учреждениеләрнең)

исемлеген билгели;

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (учреждениеләре) уңайлыклар күрсәтү сыйфаты турында мәгълүмат җыю, йомгаклау һәм анализлауны башкара торган оешма (алга таба – оператор) өчен техник мәсьәләне эшләп чыгарыр өчен тәкъдимне формалаштыра, эшләрне, уңайлыкларны сатып алу турында документлык проектларын, шулай да Министрлык оператор белән төзи торган дәүләт контракты проектларын карап тикшерүдә катнаша;

сыйфатын сынау критерийларын билгеләп куя (федераль законнар билгеләп куя торган гомуми критерийларга өстәп);

иҗтимагый фикерне табу, йомгаклау һәм анализлау, социаль уңайлыклар күрсәтә торган оешмаларның (учреждениеләрнең) рейтингларын төзү буенча эшне оештыра, шул исәптән коммерциячел булмаган социаль юнәлешле оешмалар, профессиональ берләшмәләр һәм башка экспертлар белән формалаштырылган рейтинглар;

Министрлыкка сыйфатны бәйсез сынау нәтиҗәләрен, шулай да оешмаларның эшен яхшырту турында тәкъдимнәрне җибәрә.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый совет гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең, шулай да дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмаларның тәкъдимнәре нигезендә рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Иҗтимагый совет әгъзалары составында формалаштырыла. Иҗтимагый советның шәхси составын Министр раслый.

3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә 5 кешедән ким түгел һәм 30 кешедән артык түгел составта формалаштырыла.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар керергә мөмкин, шул исәптән иҗтимагый оешмаларның һәм башка социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның вәкилләре булган. Шул ук вакытта аларның профессиональ сыйфатлары, шул исәптән Иҗтимагый совет алдына куелган сораулар турында фикер алышыр өчен кирәк булган туры килә торган белем, биредәге өлкәдә эш тәҗрибәсе, исәпкә алына.

Биредәге пунктның беренче абзацында язылган шәхесләр белән бергә Иҗтимагый советның составына Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән шәхесләр Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысын тәшкил иткән күләмдә кертелә.

Иҗтимагый совет составына элек Русия Федерациясе дәүләт вазифаларында, Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, муниципаль вазифаларда һәм муниципаль хезмәт вазифаларында урнашкан шәхесләр керергә мөмкин, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынан биштән бер өлешеннән артык булмаган күләмдә.

3.4. Русия Федерациясе дәүләт вазифаларында урнашкан шәхесләр, Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, муниципаль вазифаларда һәм муниципаль хезмәт вазифаларында урнашкан шәхесләр, суд карары нигезендә эшкә яраксыз булып танылган шәхесләр, судка түләнмәгән яисә бетерелмәгән тартылуга ия булган шәхесләр, шулай да “Русия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 2005 ел 4 апрель № 32-ФЗ Федераль законына туры китереп Русия Федерациясе Иҗтимагый палатасының әгъзалары була алмый торган башка шәхесләр Иҗтимагый советның әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирүдә сайланалар, әгәр алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә. Иҗтимагый советның рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турында карар Иҗтимагый совет утырышы протоколы белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын азат итү турында сорау Министр мөрәҗәгатье буенча карап тикшерелә, шулай да аларның шәхси гаризалары яисә Иҗтимагый советның барлык әгъзаларыннан биштән бер өлеше тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет белән карап тикшерелә.

Иҗтимагый совет әгъзалырының гомуми саныннан яртысыннан артыгы карар өчен тавыш бирсә, карар кабул ителгән булып санала.

3.6. Түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләте туктый:

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гаризаны биргәнгә;

ул сәламәтлек хәле буенча, Иҗтимагый совет эшеннән үзеннән-үзе чыгу яисә башка сәбәпләр буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганга;

аның ягына суд белән чыгарылган гаепләү карары законлы көченә кергәнгә;

законлы көчкә кергән суд карарының нигезендә аны эшкә яраксыз яисә билгесез юкка чыккан булып тану;

ул әхлак нормаларын тупас бозганга – утырышта булган Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан тавышларның күбесе белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Русия Федерациясе гражданлыгы туктаганга;

Иҗтимагый совет утырышларының эшендә нигезле сәбәпсез системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) катнашмаганга;

Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасарының йөкләмәләрен нигезле сәбәп буенча системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) башкармаганга;

аны Русия Федерациясе дәүләт вазифасына, Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясенең башка субъектларындагы дәүләт

гражданлык хезмәте вазифасына, муниципаль вазифага яисә муниципаль хезмәт вазифасына билгеләгәнгә;

ул чит ил гражданлыгын алганга.

3.7. Иҗтимагый советта әгъзалыкны туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язу гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәис урынбасарының гаризасы нигезендә кабул ителә торган Министр карарына туры китереп, шулай да биредәге Кагыйдәнамәнең 3.6 пунктында язылган шартлар килеп чыккан очракта башкарыла.

Иҗтимагый советның әгъзасы сәламәтлек хәле аркасында, аның ягына суд белән чыгарылган гаепләү карары законлы көченә кергәнгә, Русия Федерациясе гражданлыгын туктатканга эш башкара алмый торган очракта Иҗтимагый советның әгъзасы Иҗтимагый советның рәисенә яисә рәис урынбасарына бу фактлар турында хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләте Министр карарына туры китереп Иҗтимагый совет рәисенең гаризасы буенча түбәндәге очракларда туктатып торыла:

Русия Федерациясенең җинаять һәм процессуаль законнары белән билгеләп куелган тәртиптә аңа җинаять башкару гаебен кую;

аңа административ арест буларак административ җәза билгеләү;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгаручы (вәкилле) органының депутатларына кандидат, җирле үзидарә органында сайланган вазифага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы вәкил яисә вәкаләтле вәкил буларак теркәү, шулай да ул Русия Федерациясендә референдумны үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хаклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы хаклы:

Министрлык инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәлләрдә” һ. б.) катнашырга, ләкин дәүләт серен тоткан мәгълүматларны, шәхси мәгълүматларны һәм чикләнгән рөхсәтле мәгълүматны куллану белән бәйле федераль законнарга туры китереп рөхсәте чикләнгән чаралардан башка;

аналитик язулар, докладлар һәм башка информацион-аналитик материалларны инициативалы тәртиптә хәзерләп Иҗтимагый советка җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн повесткасы сорауларын карап тикшерүдә катнашыр өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган шәхесләрнең кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзаларыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән боерыкларны башкарырга;

биредәге Кагыйдәнамәдә язылган Иҗтимагый совет эшенең тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында үзе булып катнашырга;

Иҗтимагый советка йөкләнгән мәсьәләләрне чишәр өчен Иҗтимагый совет кора торган экспертлар, эшчеләр төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнарының эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үзенең эшен Иҗтимагый совет рәисе вәкилләү буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программаларга туры китереп оештыра.

5.2. Иҗтимагый советның эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлыкның тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.

5.3. Иҗтимагый советның утырышлары бер кварталга бер тапкырдан ким булмыйча үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар протокол белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшләп чыгара торган һәм “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшләп чыгара торган һәм бу башкарма хакимияте органнары карамагындагы иҗтимагый советларның утырышларында башлангыч фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокук актлар һәм башка документлар составын раслау турында” 29 март 2013 ел № 214 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган бу хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советларның утырышларында башлангыч фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокук актлар һәм башка документлар исемлегендә язылган һәм Министрлык эшләп чыгарган норматив хокук акт проектларына һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында билгеле тәртиптә теркәүгә җибәрелә торган Министрлыкның норматив хокук актларына Иҗтимагый совет йомгагын бирү максаты белән үткәрелергә мөмкин.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, Иҗтимагый совет әгъзаларының саны өчтән ике өлешеннән ким булмаса, хокуклы булып санала. Иҗтимагый советның әгъзасының үзе утырышта катнашу мөмкинлеге булмаса, көн повесткасына кертелгән сораулар буенча үзенең тавышын һәм үзенең фикерен, Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретарен алдан белдереп, язу формасында, факсимиле яисә электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшырырга хаклы. Утырышта була торган Иҗтимагый совет әгъзалар санына Иҗтимагый советның башка әгъзаларына үзләренең тавышларын ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары кушыла.

Биредәге Кагыйдәнамәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокук акт проектларын (норматив хокук актларны) карап тикшерү

аларны Министр белән Иҗтимагый советка җибәрү көненнән бирле ун календарь көне эчендә башкарыла. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый советның йомгакларын чыгару максаты белән тавыш бирүне үткәрү Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру формасында үзеннән башка тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары, имзалый торган протоколга сораштыру нәтиҗәләрен кертү белән башкарыла ала. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яисә хәбәрләрне җибәрү һәм кабул итүенең хакыйкыйлыгын һәм аларның документаль раславын тәэмин итә торган башка элемтә аша документлар алышу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Үзеннән башка тавыш бирүне үткәрү очрагында тәкъдим ителә торган көн повесткасы, Иҗтимагый совет йомгагы чыгарылырга тиеш булган норматив хокук акт проекты (норматив хокук акты) Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, барлык башка әгъзаларына тавыш бирүне үткәрү датасына кадәр җиде календарь көннән ким булмыйча алдан җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк булганда Министрлыктан карап тикшерелә торган норматив хокук акт проекты (норматив хокук акты) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүматны сорап алалар.

Иҗтимагый советның карарлары тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителәләр.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе үткәрә, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советка йөкләнгән максатларына, бурычларына, вәкаләтенә туры китереп кабул ителә торган карарлар тәкъдим характерын йөртә һәм Иҗтимагый совет утырышы протоколыннан өземтә буларак яисә Иҗтимагый совет карары буенча башка ысул белән кызыксынган шәхесләргә исәпкә алуга җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эше турында мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый советның сайтына яисә Министрлык сайтының битенә кертелә.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшенең гомуми җитәкчелеген башкара;

Иҗтимагый советның эш планнарын һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә планларга үзгәрешләр хәзерли һәм аларны Иҗтимагый советка раслауга тапшыра;

Иҗтимагый советның утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн повесткасын раслый;

Иҗтимагый советның тәкъдимнәрен, протоколларын һәм башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларының үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эше, рәискә йөкләнгән максатлар һәм бурычлар чикләрендә Иҗтимагый совет әгъзаларына боерыклар бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запрослар, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшен тәэмин итәр өчен башка кирәкле функцияләрне башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисенең рәсми булмау вакытында рәиснең функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын хәзерләвен оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн повесткасын төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслауга тапшыра;

Иҗтимагый совет эшен тәэмин итәр өчен Иҗтимагый совет рәисе боерыгы буенча башка кирәкле функцияләрне башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материалларны һәм карар проектларын хәзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларын Иҗтимагый советны үткәрү урыны һәм вакыты, көн повесткасы турында белдерә, аларны кирәкле мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Министрлыкның оештыручан үзара эшен тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшенең документ-техника тәэмин итүен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларының протоклларын рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның контролен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларының повесткасын төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга сорауларны хәзерләр өчен Иҗтимагый совет әгъзалары эш, экспертлар төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшергә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары ризалыгы буенча Иҗтимагый совет составына керми торган белгечләрне материалларны хәзерләүгә тарта алалар.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет карап тикшерә торган сораулар буенча кирәкле мәгълүматларны һәм йомгакларны тапшырыр өчен башкарма органнарының, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чараларының вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында була алалар.

5.13. Иҗтимагый совет карап тикшерүенә тапшырылган материаллар Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән соңга калмыйча аларның карап тикшерүе уйланылган урында Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән ризалана.

5.14. Иҗтимагый совет эшенең техник һәм оештыручан тәэмин итүен Министрлык тәэмин итә.